РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.03.2024 Буа шәһәре № 76/Бк-к

«Хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы
нормаларын үз эченә алган башка норматив
актларның үтәлешенә ведомство контроле
турындагы нигезләмәне раслау турында»
2022 елның 4 февралендәге 31/Бк-к номерлы
Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 353.1 статьясына, «Татарстан Республикасында хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында» 2019 елның 14 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, 2022 елның 1 февралендәге 20 номерлы «Хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәүгә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен тикшерү кәгазьләре формаларын (контроль мәсьәләләре исемлекләрен) раслау турында» Хезмәт һәм мәшгульлек буенча Федераль хезмәт боерыгына (21.08.2023 ред.) таянып, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив актларның үтәлешенә ведомство контроле турындагы нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 4 февралендәге 31/Бк-к номерлы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ведомство контролен үткәргәндә «Хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен тикшерү кәгазьләре формаларын (контроль мәсьәләләре исемлекләрен) раслау турында» 2022 елның 1 февралендәге 20 номерлы Хезмәт һәм мәшгульлек буенча Федераль хезмәт боерыгы белән расланган контроль мәсьәләләр исемлеген кулланырга киңәш ителә.»

2. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2022елның 4 февралендәге

31/Бк-к номерлы карары белән расланган хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контроле турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тикшерү үткәргәндә вәкаләтле вазыйфаи затлар «Хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен тикшерү кәгазьләре формаларын (контроль мәсьәләләре исемлекләрен) раслау турында» 2022 елның 1 февралендәге 20 номерлы Хезмәт һәм мәшгульлек буенча Федераль хезмәт боерыгы белән расланган тикшерү кәгазьләрен тутыралар.»

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш http://buinsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов